СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«31» октябрь 2024 ел

№ 131

Балтач муниципаль районы Чепьяавыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чепьяавыл җирлеге башлыгының, Чепьяавыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 138нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында
(2023 елның 27 феврале 87нче номерлы, 2024 елның 17 июле 124нче номерлы үзгәрешләре белән)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 нче сентябреннән 829 нчы номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2024 елның 29 нчы октябре 288 нче номерлы карары» һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепьяавыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Чепьяавыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепьяавыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепьяавыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба - Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 2018 елның 25 декабрендәге 138 нче номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепьяавыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «13323» санын «13990» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепьяавыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү Тәртибенең ( 1нче кушымта) 1 пунктында «18260» санын «19173» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 01.01.2025 елында үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Чепья авыл җирлеге башлыгы

А.Г. Нотфуллин